*МБББУ «Балык Бистәсе 2нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»*

# «Кауры́й КАЛӘМ»



ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ
И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
2021
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ
ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

***Февраль-2021***

# Муса Җәлилнең туына 115 ел...

Муса Җәлил... Бу исемне телгә алуга, күз алдына, нindидер, гадәттән тыш кеше килеп баса. Ул – ялкынлы шигырьләр язган шагыйрь дә, илнең азатлыгы өчен көрәшкән курку белмәс яугир дә, үлемне ирләрчә каршылаган каһарман да. Сугышка кадәр үк бик күп шигырьләр, җырлар, без барыбыз да яратып укыган “Хат ташучы” поэмасы, “Алтынчәч”, “Илдар” либреттолары белән үзен талантлы шагыйрь итеп таныткан Муса Җәлил, Бөек Ватан сугышы башлану белән, фронтка җибәрүләрен сорый. Аның үтенече канәгатьләндерелә. Ләкин 1942 елның җәендә Волхов фронтында, дошман чолганышында калып, авыр яраланган хәлдә, фашистлар кулына әсирлеккә эләгә. Әнә шулай аның лагерь тормышы башлана. Шагыйрь әсирлектә дә көрәшне туктатмый. Яшерен оешмага керә, аның җитәкчеләреннән берсе була, бик күп әсирләр белән лагерьдан качу һәм партизаннарга барып кушылу ниятен тормышка ашырырга уйлый. Бер хыянәтче аларның серләрен фашистларга хәбәр итә. Шуннан соң Җәлилне һәм аның иптәшләрен Моабит төрмәсенә ябалар. Шагыйрь анда да туган иленә тугрылыклы булып кала. Искиткеч рухи ныклык күрсәтә. Үлем җәзасы көтеп торганда да туган илгә, халыкка тирән мәхәббәт белән сугарылган, фашистларга көчле нәфрәт белдергән шигырьләр язып, аларны үзе ясаган кечкенә дәфтәрләргә теркәп бара. Туган илгә аның ике дәфтәре кайтты. Аларны бөтен дөньяда “Моабит дәфтәрләре” дигән исем белән беләләр. Шагыйрьне үтерсәләр дә, фашистлар аның ялкынлы җырларын, көчле рухын юк итә алмады. Муса Җәлил илгә җыр булып кайтты. Муса Җәлил исемен, илебез халкы гына түгел, бөтендөнья халкы горурлык белән искә ала. Аның көрәше, эшчәнлеге – кыюлык һәм батырлык үрнәге. Быел Муса Җәлилнен туына 115 ел тулды, шул уңайдан мәктәбебездә “Гомерем минем моңлы бер җыр иде” әдәби-музыкаль кичә үтте һәм “ Мин Муса Җәлилне укыйм” әдәби марафоны башланды. Актлар залында каһарман шагыйрьнең шигырьләре яңгырады, тормыш юлы буенча презентация күрсәтелде. Бу кичәнең максаты: Муса Җәлилнең әсәрләрен пропагандалау, аның шигырьләренең бөеклеген дәлилләү; Туган илгә, туган телгә мәхәббәт тәрбияләү.




**Галавиева Алинә, 10а класс**

# Изге Вәли көне




Ундуртенче февраль көнне бөтен дөнья изге Валентин бәйрәмен үткәрә. Бү бәйрәм кайдан килеп чыккан икән? Бу бәйрәмне, кеше унбиш гасырдан артык уткәрә торган булган. Изге Валентин бәйрәме бик матур риваять белән бәйле. Ике йөз алтмыш утызынчы елны Клавдий Икенче императорның тыюлыгына карамстан Римскрй империи легионерлары узләренең сөйкемле кешеләре белән никаh укытканнар. Никаhны вәгазче христиан валентин укыткан. Ул елларда легионерларга өйләнергә рөхсәт юк иде. Чөнки сугышчыларның хәрби рухларын саклау hәм көчле булсын император шундый указ чыгарган. Изге Валентин гачлыкларга булышырга тырышкан hәм аларга өйләнергә никаh укыткан. Клавдий Икенче моны белгәч, вәгазне төрмәгә ташлаган, ә анан соң, җәза указы имзалган Валентинның соңгы көннәре дә бик романтик уткән. Риваят буенча төрмә караучының сукыр кызы гашик булган ләкин. Валентик аның мәхәбәтенә ризалык әйтә алмаган. Улер алдыннан гына, ун өченче февральдә бик матур мәхәбәт хатын язган. Кыз шушы мөхәббәт хатын укыган соң курә башлаган. Шуннан бирле изге Валентин көнне, мәхәбәт хатларын язалар. Алар валентинкалар дип аталар.

hәр елны безнең мәктәптә бу бәйрәм уткәрелә. Бу көнне беренче этаж да музыка уйный. Шунлыктан hәр кешенең кәефе күтәрелә. Укучылар йөрәк рәвешендә плакатлар ясыйлар. Шунның мәктәп почтасы эшлий. Алар валентинкаларны уз адресатларына таплыралар. Бу бәйрәмнең ахырында дискатека уткәрелә. Бу көн матур hәм кызыклы утә.

**Сафин Вильдан 8А**

# *Аларны кию бәхетенә ирешүе дә ни тора!*

Әби – бабаларыбыздан безгә рухи мирас белән бергә матди мәдәният өлкәсенә караган мирас та калган. Шундыйларның берсе— халыкның өс киеме. Өс киеменең бик борынгы төрләре, әлбәттә, безгә килеп җитмәгән. Ә инде җиткән кадәресе халкыбызның кабатланмас иҗади көчкә ия булуын күрсәтә. Гасырлар буена халык бу эшкә үзенең кул көчен генә түгел, бәлки матурлыкка омтылышын, хыялын, эстетик зәвыгын да салган.

Төрле җирләргә таралып, шактый тотрыклы төркемнәр булып яшәүче татарларның киемнәре, әлбәттә, бер төрле генә булып формалашмаган. Һәр төркемнең үзенә генә хас тарихы булган кебек, аларның гадәти киемнәрендә дә үзенчәлекләр бар. Бу үзенчәлекләрнең барлыкка килүенә табигать үзе, икътисади шартлар, дин һәм күрше халыклар белән аралашу бик нык тәэсир итә. Һәрхәлдә, XIX гасырның урталарына кадәр татар халкының гадәти киеме җирле билгеләрен шактый тотрыклы саклый. Бу бигрәк тә хатын-кызлар киемендә (күлмәкләренең бизәлүендә, баш киеме формаларында) сизелә.Туган телләр һәм халыклар дуслыгы елы кысаларында мәктәбебездә “Милли кием – халкымның күңел көзгесе” исеме белән милли киемнәр тәкъдим итү булды



**Мусина Резеда 10 А**

# Конкурс "Песни и строя"

В нашей школе конкурс «Смотр песни и строя» проводится по сложившейся традиции ежегодно перед 23 февраля. Каждый класс задолго до мероприятия начинает готовиться к нему. Задача перед всеми стоит одна: показать свои только самые положительные качества – ответственность, умение слаженно работать в коллективе, любовь к Родине, готовность встать на её защиту в случае необходимости.

И вот наступает тот самый день, когда пора показать, свою военную подготовку. В этом году конкурс прошел 20 февраля. На мероприятие кроме учеников и педагогов пришли и почетные гости: начальник отделения военного комиссариата Рыбно-Слободского муниципального района, майор - Юрий Владимирович Резун, ветеран военной службы, майор - Шарафиев Саубан Гумарович, сержант запаса воздушно-десантных войск Гайниев Динар Наилевич, заместитель руководителя исполнительного комитета по социальным вопросам – Вафина Айгуль Камилевна, методист отдела образования - Мотыгуллина Лейсан Рауфовна, директор школы – Талалаева Мунира Робертовна, директор ДОСААФ – Хамматов Ильнур Зиннурович . Им предстояло оценивать конкурс и подводить итоги месячника военной подготовки.

В конкурсе не было равных строям: 10а , 9б и 5 б классов. Эти ребята были отмечены грамотами. Позже были подведены итоги месячника патриотизма и награждены грамотами победители и призеры конкурсов: рисунков, стихов, по сборке автомата Калашникова и других мероприятий.



В заключении хотелось бы добавить пожелание:

«Пусть небо будет голубым,
Пусть в небе не клубится дым,
Пусть пушки грозные молчат
И пулемёты не строчат
Чтоб жили люди, города...
Мир нужен на земле всегда!»

Пусть же над нами всегда будет мирное небо!

**Хамматов Ильфат и Власов Максим, 7а класс**

# «Халыкара туган тел көне”

Җыр булырлык сүзләр биргән,

Туган телем, рәхмәт сиңа!

21 февральдә дөньякүләм туган тел көне билгеләп үтелә. Һәркем өчен телләрнең иң кадерлесе булып, ул беренче сөйләшә башлаган ана теле торырга тиеш. Халыкара туган тел көнендә барлык телләр дә, тигез дип таныла, чөнки аларның һәркайсы кеше язмышы өчен җавап бирә һәм без аны сакларга тиешбез. Телләрне саклау һәм үстерү максатыннан уздырыла торган бу бәйрәм елдан-ел үзенең даирәсен киңәйтә һәм укучыларның яраткан бәйрәменә әйләнеп бара. Шул уңайдан мәктәбебездә “Җырлыйм татар телендә” дигән акция үткәрелде. Бу көнне мәктәбебезнең актлар залында һәр сыйныф татар телендә яраткан җырларын яңгыратты.




# Татар халык уеннары белән танышабыз

Безнең татар халкы күңел ачарга да яраткан. Моны төрледә-төрле кызыклы уеннар дәлилли.

**1) “Кәрия-Зәкәрия” уены.**

Балалар кулга-кул тотынышып түгәрәкләнеп басалар. Уртага бер бала чыга. Түгәрәктәгеләр бер якка хәрәкәт итеп җырлыйлар. Җырларда уртадагы баланың укуда, хезмәттә, җыр-биюдә булган сәләте, уңганлыгы мактала:

***Бу бик яхшы биюче,***
***Бу бик яхшы биюче,***
***Аның биюе матур,***
***Аннан үрнәк алыгыз.***

Җырдан соң түгәрәктәгеләр туктап калалар, кул чабып, такмак әйтәләр:

***Кәрия-Зәкәрия, коммая,***
***Кәрия-Зәкәрия, коммая,***
***Кәри комма, Зәкәр комма,***
***Зәкәрия коммая.***

Бу вакытта уртадагы бала бер иптәшен алып әйләнеп тора. Әйләнеп туктагач, чакырган иптәшен калдырып, түгәрәккә баса. Тагын җыр башлана:

***Бу бик яхшы җырлаучы,***
***Бу бик яхшы җырлаучы.***
***Аның җырлавы матур,***
***Аннан үрнәк алыгыз.***

Шулай йөзүче, укучы, буяучы һ.б.

# “Яшь каләм тибрәтүчеләр”

Татар булуым белән бәхетле

И Туган тел, и матур тел

Әткәм , әнкәмнең теле

Дөньяда күп нәрсә белдем

Син Туган тел аркылы

(Г.Тукай)

**“Татар теле — иң бай һәм иң борынгы төрки телләренең берсе. Берләшкән Милләтләр Оешмасының карары нигезендә, жир шарындагы 6500 телнең 14е халыкара тел дип игълан ителгән. Бу телләр арасында татар теле дә бар. Бүгенге көндә татар теле — зур үсеш алган телләрнең берсе. Галимнәр әйтүенчә, татар телендә ярты миллионлап сүз бар” , - диелгән интернет челтәрләрендә.**

**Минем туган телем - татар теле. Әни дип телем ачылган. Өйдә без гел татар телендә сөйләшәбез. Әнием Казан дәүләт университетының татар журналистикасы факультетын тәмамлады. “Авыл офыклары” район газетасында эшли. Сүзләрне дөрес әйтмәсәк, ул безне хәзер төзәтеп куя. Авыл матбугатта басылып чыккан язмаларын укырга яратам. Мәктәптә татар телен, әдәбиятын өйрәнү дә бик ошый миңа. Дәү әти белән дәү әнигә безнең татарча сөйләшкәнебезне яраталар. Сеңлем белән русча сөйләшеп китсәк, без русча белмибез, дип куялар. Беләләр ул телне, тик безнең ана телендә сөйләшүебезне телиләр алар.**

Әнием китапханәдән алып кайткан татар телендәге әкият, хикәяләр, мажараларны бик теләп укыйбыз. Сеңлем белән шулай яңа сүзләр өйрәнәбез, тел байлыгыбызны арттырабыз. Минемчә, үз телеңә мәхәббәт иң беренче гаиләдән башлана. Без кечкенәдән үз телебезне яратып үсәргә, һәм бездән соңгы буынга тапшырырга тиешбез. Мин татар булуым һәм бу телдә иркен сөйләшә алуым белән бәхетле.



Регина Зарипова 7А

## «КАГЫЙДӘЛӘР ИЛЕНДӘ»

### Татар телендә килешләр

Татар телендә **6 килеш** бар.

| Килешләр | Сораулар | Кушымчалар | |
|---|---|---|---|
| | | калын | нечкә |
| Баш килеш | кем? нәрсә? | --- | ---- |
| Иялек килеш | кемнең? нәрсәнең? | - ның | - нең |
| Юнәлеш килеше | кемгә? нәрсәгә? | - га, - ка | - гә, - кә |
| Төшем килеше | кемне? нәрсәне? | - ны | - не |
| Чыгыш килеше | кемнән? нәрсәдән? кайдан? | -нан, -дан, - тан | - нән, -дән, - тән |
| Урын-вакыт килеше | кемдә? нәрсәдә? кайда? | - да, - та | - дә, - тә |

MyShared

## МӘЗӘКЛӘР

**Физкультурадан зачет тапшырыр алдыннан укытучы:**

**Бу сезгә математика түгел, монда баш белән уйларга кирәк.**

**-Эти, будет нэрсэ?**

**-Будет песи улым!**

**-Эти бу нэрсээ?**

**-Бу песи улыыым!!**

**-Этиии, бу нэрсэээ!?**

**-Песи**

**-Эти, нэрсэ буу?!**

**-Белииим**

**-Бу песи эти =) )**

**Тулы гәүдәле хатын бер малайга мөрәҗәгать итә:**
**– Үскәнем, бу капка аша мин паркка үтә алам-мы?**
**Малай, икеләнеп кенә:**
**– Белмим шул... Әле күптән түгел генә печән төягән машина үткән иде аныкы...**

***МБББУ «Балык Бистәсе 2нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең» редакциясе***

МУСА ҖӘЛИЛНЕН ТУУЫНА 115 ЕЛ –Галавиева Алинә

ИЗГЕ ВЭЛИ КӨНЕ– Сафин Вильдан

**МИЛЛИ КИЕМНӘР - Мусина Резеда**

*КОНКУРС ПЕСНИ И СТРОЯ– Власов Максим и Хамматов Ильфат*

**ЯШЬ КАЛӘМ ТИБРЭТҮЧЕЛӘР– Зарипов Регина**

МӘЗӘКЛӘР– Сулейманов Раниль

**КАГЫЙДӘЛӘР ДӨНЬЯСЫНДА– Халилова Адиля**

**ВЕРСТКА– Мусина Резеда**


Адрес редакции:

422650, Республика Татарстан, Рыбно-Слободский район, пгт. Рыбная Слобода, ул. 60-лет Октября, д. Телефон: +7(843)-612-35-08

E-Mail: S.Rs@tatar.ru

Гл. редактор: Шигапова А.М

Зарипова Г. Ж.


